**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“26” ноябрь 2021 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлыТатарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1.Җирлек территориясен төзекләндерү :
- Чишмәне койма белән әйләндеру (төзелеш материаллары сатып алу , транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Чишмәгә төшү юлына баскыч ясау һәм урнаштыру(төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү.;

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:
-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- авыл территориясен чистарту, хезмәт өчен түләү.

4. Җирлек территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- электр белән тәэмин итүнең автоном резерв чыганагын сатып алу
(бензогенератор 380 В)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Сибгатуллин Д.Р.